**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 29 апрель № 266

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары төзүнең тәкъдим ителә торган критерийларын раслау хакында» 2015 ел, 30 май, 388 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары төзүнең тәкъдим ителә торган критерийларын раслау хакында» 2015 ел, 30 май, 388 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары төзүнең тәкъдим ителә торган критерийларына кушымталарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары төзүнең тәкъдим ителә торган критерийларына 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлә);

Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары төзүнең тәкъдим ителә торган критерийларына 3 нче кушымтаның унынчы абзацында «җирле үзидарә органы вазыйфаи затының, участок полициясе вәкаләтле вәкилләренең һәм балигъ булмаганнар эшләре буенча инспекторларның» сүзләрен «тәртип саклау буенча җәмәгать пункты эшчәнлегендә катнашучы җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларының һәм тәртип саклау буенча җәмәгать пунктына беркетелгән полиция хезмәткәренең» сүзләренә алмаштырырга;

Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары төзүнең тәкъдим ителә торган критерийларына 4 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары төзүнең тәкъдим ителә торган критерийларына 2 нче кушымта (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 29 апрель, 266 нчы карары редакциясендә)

**Гражданнарны кабул итү көннәре һәм вакыты турында эленмә такта (белдерү) ҮРНӘГЕ**

Эленмә тактаны (белдерүне), гражданнарны тәртип саклау буенча җәмәгать пунктында кабул итү көннәрен һәм вакытын, шулай ук җирле үзидарә органнары вазыйфаи затларының фамилиясен, исемен, әтисенең исемен, полиция хезмәткәрләренең фамилиясен, исемен, әтисенең исемен, махсус званиесен, хезмәт күрсәтелә торган йортларның адресларын күрсәтеп, халыкка күренә торган һәм ачык җирдә тәртип саклау буенча җәмәгать пунктына керү урыны янында урнаштыру киңәш ителә.

<table>
<tr><td colspan="2">ТӘРТИП САКЛАУ БУЕНЧА ҖӘМӘГАТЬ ПУНКТЫНЫҢ<br>ЭШ РЕЖИМЫ<br><br>Көн саен 14:00 сәгатьтән алып 22:00 сәгатькә кадәр</td></tr>
<tr><td>Тәртип саклау буенча җәмәгать пункты эшчәнлеген тәэмин итүче җирле үзидарә органы вазыйфаи заты___________________________________________<br>(фамилиясе, исеме, атасының исеме)<br><br>Участок полициясенең өлкән вәкаләтле вәкиле<br>_______________________________________________<br>(махсус званиесе, фамилиясе, исеме, атасының исеме)<br><br>Түбәндәге адреслар буенча йортларга һәм йорт биләүләренә хезмәт күрсәтә:___________________________________________<br>(йортларның һәм йорт биләүләренең адреслары)<br><br>Участок полициясенең вәкаләтле вәкиле _________________<br>_______________________________________________<br>(махсус званиесе, фамилиясе, исеме, атасының исеме)<br><br>Түбәндәге адреслар буенча йортларга һәм йорт биләүләренә хезмәт күрсәтә:___________________________________________<br>(йортларның һәм йорт биләүләренең адреслары)<br><br>Җирле үзидарә органының вазыйфаи заты _________________<br>_______________________________________________<br>(махсус званиесе, фамилиясе, исеме, атасының исеме)</td><td>Гражданнарны кабул итү<br><br>сишәмбе<br>17:00 сәгатьтән алып 20:00 сәгатькә кадәр<br><br>пәнҗешәмбе<br>10:00 сәгатьтән алып 12:00 сәгатькә кадәр<br><br>шимбә<br>(ял көнендә)<br>17:00 сәгатьтән алып 20:00 сәгатькә кадәр</td></tr>
</table>

______________________

Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары төзүнең тәкъдим ителә торган критерийларына 4 нче кушымта (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 29 апрель, 266 нчы карары редакциясендә)

# ТӘРТИП САКЛАУ БУЕНЧА ҖӘМӘГАТЬ ПУНКТЫНЫҢ ЯКЫНЧА ҖИҺАЗЛАНЫШЫ

Тәртип саклау буенча бер җәмәгать пунктына исәпләгәндә якынча җиһазланыш түбәндәгеләрне тәшкил итә:

тәртип саклау буенча җәмәгать пунктының эшчәнлегендә катнашучы җирле үзидарә органының һәр вазыйфаи затына һәм тәртип саклау буенча җәмәгать пунктына беркетелгән һәр полиция хезмәткәренә бер язу өстәле;

тәртип саклау буенча җәмәгать пунктының эшчәнлегендә катнашучы җирле үзидарә органының һәр вазыйфаи затына, тәртип саклау буенча җәмәгать пунктына беркетелгән һәр полиция хезмәткәренә һәм тәртип саклау буенча җәмәгать пунктында һәр катнашучыга бер урындык;

һәр язу өстәленә бер урындык исәбеннән килүчеләр өчен урындык;

бер кием шкафы;

эш документлары бланкларын, китаплар саклау өчен бер шкаф;

автоҗавап бирү һәм керүче шалтыратуларны яздыру функциясе булган бер телефон аппараты;

эш документларын саклау өчен бер металл шкаф (сейф);

тәртип саклау буенча җәмәгать пунктының эшчәнлегендә катнашучы җирле үзидарә органының һәр вазыйфаи затына бер компьютер;

принтер, сканер һәм факсимилесы булган күп функцияле җайланма;

һәр язу өстәленә бер өстәл лампасы;

медикаментлар һәм бәйләү чаралары белән аптечка;

янгын сүндергеч.

________________________________